ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**
**10.06.2020**

Зеленодольск
шәһәре

**КАРАР**
**№ 1053**

Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының 2019 елның 17 маендагы «Гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү бердәм дәүләт системасының Зеленодольск звеносы территориаль ярдәмче системасы турында» 1073 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү бердәм дәүләт системасының Зеленодольск звеносы территориаль ярдәмче системасы турындагы Нигезләмәне гамәлдәге законнарга туры китерү максатыннан, Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының 2019 елның 17 маендагы «Гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү бердәм дәүләт системасының Зеленодольск звеносы территориаль ярдәмче системасы турында» 1073 номерлы карары белән расланган Нигезләмәнең (1 нче кушымта) 2 пунктына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә: «халыкны һәм территорияләрне гадәттән тыш хәлләрдән яклау өлкәсендә» сүзләрен «халыкны һәм территорияләрне гадәттән тыш хәлләрдән яклау, шул исәптән су объектларында кешеләр иминлеген тәэмин итү буенча» сүзләренә алмаштырырга.
2. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составындагы Зеленодольск муниципаль районы мәгълүмат сайтында (http://zelenodolsk.tatarstan.ru) урнаштырырга.
3. Әлеге карар үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Җитәкченең беренче урынбасары А.В. Старостин